РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 157 от «19»02 2016 г.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районының социаль-
икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча
эшче төркем турында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 18 декабрендәге 534 номерлы «Татарстан Республикасы шәһәр округлары муниципаль районнары дәрәҗәсендә социаль-икътисадый үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» боерыгы нигезендә

к а р а р б и р ә м:

1. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча эшче төркем төзергә.
2. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү буенча эш төркеме турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. 2 нче кушымта нигезендә эшче төркем составын расларга (килешү буенча).
4. Эшче төркемгә 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләргә тәкъдим итәргә.
5. 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе өстендә эшнең календарь планын 3 нче кушымта нигезендә расларга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»челтәрендә урнаштырырга.
7. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче С.М.Гыймранов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесенең
«19» 02. 2016 № 157 карарына
1 нче кушымта

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча эшче төркем турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) районның социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә урнашкан бюджет учреждениеләре, шәхси эшмәкәрләр, оешмаларның (алга таба – оешмаларның) оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә эшчәнлеген координацияләүче консультатив орган булып тора.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе хокукый актлары, Татарстан Республикасы хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

3. Эшче төркемнең эшчәнлеге эшче төркем әгъзаларының эштә тигез хокуклылык, коллегиальлек, ачыклык һәм ирекле катнашу принципларына нигезләнгән.

4. Үз эшчәнлеген гамәлгә ашырганда эшче төркем Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнары, оешмалар, сәяси партияләр һәм иҗтимагый, профсоюз оешмалары һәм берләшмәләре, шулай ук халык белән хезмәттәшлек итә ала.

5. Эшче төркемнең төп максаты-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенең кыска, урта һәм озак сроклы проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр эшләү.

Эшче төркемнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- озак сроклы перспективага Мамадыш муниципаль районын үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен һәм төп стратегик максатларын билгеләү;

социаль-икътисади үсешнең ресурс потенциалын бәяләү;

- үсешнең өстенлекле юнәлешләре һәм төп стратегик максатлары кысаларында билгеләү;

идеяләр һәм инициативалар тудыру, тәкъдимнәрне карау, фикер алышу һәм бәяләү, алар буенча тиешле киңәшләр эшләү;

Стратегия проектын, башка стратегик һәм программа документларын эшләү һәм формалаштыруны координацияләү;

стратегияне, башка стратегик һәм программа документларын гамәлгә ашыруны мониторинглау.

6. Эшче төркемнең төп функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

- «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) дәрәҗәсендә социаль-икътисадый үсешне стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыру буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында»Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 18.12.2015 № 534 боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы

Мамадыш муниципаль районының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш стратегиясен (алга таба Стратегияне) эшләүне оештыру һәм координацияләү;

- стратегиянең конкрет бүлекләрен формалаштыру буенча җаваплы башкаручыларны һәм срокларны билгеләү;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының урта сроклы перспективага үсешенең мөһим проблемаларын ачыклау һәм анализлау, аларны хәл итү стратегиясен һәм тактикасын эшләү, аларны гамәлгә ашыруның хокукый, икътисади һәм оештыру механизмнарын булдыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- аларны Стратегиягә кертү өчен тәкъдим ителгән материалларны карау.

7. Эшче төркем үз функцияләрен тормышка ашыру максатында:

- федераль башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, район предприятиеләреннән һәм оешмаларыннан билгеләнгән тәртиптә эшче төркем компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат сорарга һәм алырга;

- үз утырышларына бизнес, фән, социаль өлкә һәм җәмәгатьчелек вәкилләрен, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары белгечләрен чакырырга;

- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше проблемаларын хәл итү вариантларын өйрәнү һәм әзерләү өчен квалификацияле белгечләр җәлеп итеп эксперт комиссияләре төзергә;

- презентацияләр, семинарлар, конференцияләр, җыелышлар үткәрүне оештырырга.

8. Эшче төркемнең җитәкчесе - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.

9. Эшче төркемнең җитәкчесе:

- эшче төркем утырышының көн тәртибен раслый;

эшче төркем утырышларында рәислек итә;

эшче төркем утырышларын алып бара;

эшче төркемне башкарма хакимият органнары, гражданнар берләшмәләре, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә.

10. Эшче төркем утырышлары стратегияне эшләү һәм аңа үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертү (коррекцияләү) мәсьәләләрен хәл итү кирәк булган саен үткәрелә.

11. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен эшләү, утырышлар әзерләү, эксперт һәм аналитик эшләр үткәрү, тәкъдимнәр эшләү өчен эшче төркем эшче төркемгә йөкләнгән бурычларны хәл итү мәсьәләләрен консультацияләр, өйрәнү, әзерләү һәм карау өчен белгечләр җәлеп итә ала.

12. Эшче төркем карары буенча аның утырышына дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре, эшче төркем караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматлар һәм нәтиҗәләр бирү өчен башка белгечләр чакырылырга мөмкин.

Җитәкче урынбасары И.М.Дарземанов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесенең
«19» 02. 2016 № 157 карарына
2 нче кушымта

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясен эшләү буенча эшче төркем составы

1. Гыймранов Салават Мәхмүт улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
2. Сабиров Шамил Мансур улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
3. Дәрҗеманов Илшат Минәсхәт улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары;
4. Смирнова Алена Петровна – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары;
5. Нәфыйков Таһир Габдулла улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге җитәкчесе;
6. Никитин Вадим Ильич –Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге җитәкчесе;
7. Сәмигуллин Ришат Роберт улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча);
8. Низамиев Фәнил Миннехарис улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тикшерү-хисап палатасы рәисе (килешү буенча);
9. Сергеев Алексей Михайлович – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;
10. Белоусов Сергей Вячеславович – милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе;
11. Гаптрахимов Ильяс Габделхай улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);
12. Габдрахманов Илдус Нурислам улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;
13. Спиридонов Степан Петрович – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы;
14. Гыйлемханов Таһир Әхмәдулла улы – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының "Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге" МУ бүлеге башлыгы;

15. Муллахмәтова Миннегөл Мирсәет кызы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы (килешү буенча);

16. Хазиев Дамир Фаязович – Мамадыш районы үзк хастаханәсе башлыгы (килешү буенча);

17. Мотыйгуллин Рифат Мәхмүт улы – шәхси эшмәкәр, Мамадыш муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

18. Юнысов Марс Мидхәт улы – фермер хуҗалыгы башлыгы, Кемешкүл авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча);

19. Хисмәтов Фирназ Фәрит улы – фермер хуҗалыгы башлыгы, (килешү буенча);

20. Галиев Рафаэль Рәшит улы – «Радуга» ҖЧҖ директоры (килешү буенча);

21. Миннәхмәтов Раиф Ринат улы –«Водоканал» ГАҖ генераль директоры, Мамадыш муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

22. Госамов Ришат Мәснәви улы – шәхси эшмәкәр, (килешү буенча )

23. Шәнгәрәев Рәис Габдельбәр улы – «Мамадыш торак-коммуналь хезмәтләр " ҖЧҖ директоры, Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы депутаты (килешү буенча);

24. Әхмәтшин Мәксут Мәхмүт улы – «ПРОСТО МОЛОКО» ҖЧҖ «Мамадыш сыр-май комбинаты» ҖЧҖ филиалы директоры, депутат Совета Мамадыш муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

25. Захаров Николай Иванович - «Татспиртпром» ГАҖ «Мамадыш спиртзаводы» филиалы директоры (килешү буенча);

26. Хаҗиев Илфат Фаяз улы – «Стройсервис» ЯАҖ генераль директоры, Мамадыш муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

27. Мостафин Ринат Сәгыйрь улы – «ПМК-Мелиорация» ҖЧҖ генераль директоры, Мамадыш муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча);

28. Фахриев Мансур Әхмәтгали улы – Мамадыш районы РайПО комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча);

29. Әгләямов Айнур Хәлим улы - «ТР Аграр яшьләр берләшмәсе” Мамадыш бүлекчәсе рәисе (килешү буенча);

30. Курамшина Гөлнур Даут кызы – «Бердәм Россия» ВВП ТРО җирле бүлекчәсе башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча).

Җитәкче урынбасары И.М.Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесенең
«19» 02. 2016 № 157 карарына

3 нче кушымта

2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе өстендә эшнең календарь планы

| № т/б | чара | вакыты |
|---|---|---|
| 1. | 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы стратегиясе проектын эшләү | 2016 елның 5 мартына кадәр |
| 2. | 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы стратегиясе проекты, шул исәптән бизнес вәкилләре, җәмәгать оешмалары, район халкы белән иҗтимагый фикер алышу | 2016 елның 15 мартына кадәр |
| 3. | Иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы стратегиясе проектын 2030 елга кадәр эшләп бетерү | 2016 елның 25 мартына кадәр |
| 4. | 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы стратегиясенә кул кую | 2016 елның 1 апреленә кадәр |

Җитәкче урынбасары И.М.Дәрҗеманов